ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е К А Р А Р

«14» август 2019 ел №1148

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 10 октябрендәге «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында»гы 1483нче номерлы карары белән расланган муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру Тәртибенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 нче карарын үтәү йөзеннән, Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 10 октябрендәге «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында»гы 1483нче номерлы карары белән расланган муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә, аның 2.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Җир кишәрлеген арендалау килешүе нигезендә стационар булмаган сәүдә объектлары гамәлдә булу срогы чыкмаган 2015 елның 1 мартына кадәр төзелгән килешүләр буенча урнаштырыла.

Күрсәтелгән датага гамәлдә булган һәм стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруны күздә тоткан җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенең гамәлдә булу срогы чыккач, хуҗалык итүче субъект белән әлеге Тәртипнең 2.2.2 пунктчасы нигезендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру турында килешъ төзелә.».

2.Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетында бастырырга һәм Лениногорск муниципаль районы районы рәсми интернет-сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Җитәкче Н.Р.Залаков

И.Р.Хәйбрахманов
5-44-72